ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2024 ел Баулы шәһәре №137

2025 елда Баулы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны түләүсез туклану белән тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, СанПин 2.4.5.2409-08 гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә сәламәт туклануны оештыру өлешендә укучыларны тукландыруны оештыруга, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга карата таләпләрне үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елда түләүсез туклану белән тәэмин итәргә:

- бер үк вакытта Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күпбалалы гаиләләрдәге балаларны;

- Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы “Баулы муниципаль районында “Гаилә” балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют “ ДКУ балаларын;

- Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы инвалид балаларны.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2024 елда җирле бюджетны үтәү процессында гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны түләүсез тукландыруны тәэмин итүгә ташламалар бирү чараларына чыгымнарны каплауга финанс чаралары табарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров